**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

№ 342-р 23 июль 2015 ел

Аерым категория гражданнарны социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итү буенча халык арасында аңлату эшен оештыру буенча эшче төркем булдыру турында

"Аерым гражданнарны социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итү турында" 03.07.2015 ел, № 1429-р Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгын үтәү һәм әлеге юнәлештә эш алып бару буенча атналык мониторинг үткәрү максатларында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Атналык мониторингны гамәлгә ашыру буенча эшче төркем булдырырга:

Галәүтдинова А. С. - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары, эшче төркем җитәкчесе;

Йосыпов М.Р. - "Нурлат РҮХ" ДАССОның баш табибы, эшче төркем җитәкчесе урынбасары (килешү буенча).

Эшче төркем әгъзалары:

Р. М. Шакирова-Нурлат муниципаль районында Пенсия фонды идарәсе башлыгы (килешү буенча)

Р. Р. Романова-Нурлат муниципаль районы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча);

Клементьев А. Л. - ТР каршындагы ЭЭМ баш бюросының 29 нчы филиалы җитәкчесе (килешү буенча);

Закуванов И. З. - "Таттехмедфарм" ДУП-ның 94нче номерлы район үзәк даруханәсе мөдире (килешү буенча)

Андарова Д.К. - Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор Идарәсенең Нурлат, Аксубай районнарындагы территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча).

2. Эшче төркемгә, районның авыл җирлекләре башлыкларына халык арасында социаль хезмәтләр җыелмасын алу кирәклеге турында аңлату эшләре алып барырга.

3. Нурлат муниципаль районында Пенсия фонды идарәсе начальнигына атна саен Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетына социаль хезмәтләр җыелмасын алу турында гариза биргән гражданнар саны турында мәгълүмат бирергә.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районының башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы                                         Р.Х. Морадыймов